**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Комсомолец  авыл җирлеге Башлыгы**

# КАРАР

“29” август 2018 ел　　　Комсомолец поселогы　　　№15

«Комсомолец авыл җирлеге бюджеты хисап
проекты үтәлеше буенча  2018 елның
1 яртыеллыгында  ачык тыңлаулар үткәрү турында».

Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районы  Комсомолец авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, «Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турындагы хисап» карары проектын тикшерүдә катнашу өчен  Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Башлыгы

## КАРАР БИРӘМ :

1. Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге бюджетының 2018 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турында Отчет»карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
2. Әлеге Карарны  29 августанда  сонга калмыйча Тукай  муниципаль районы рәсми порталында  (www.tukay.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Комсомолец  авылы җирлеге бинасы янында җиһазландырылган мәгълүмат  такталарында урнаштырырга

3.Ачык тыңлауларны уздыру көнен билгеләү :
3.1. 2018елның  3 сентябрь көнне,сәгать 10.00 уздыру;
3.2.Уздыру көне – 1 көн  ;
3.3. Уткәрү урыны  – ТР,  Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге, Яр Буе урамы, 15нче йорты  (**Комсомолец авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы,утырышлар залы)**
3.4.Сораулар ,тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, Комсомолец авылы, Яр Буе урамы, 15нче йорт, (эш көннәрендә-8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр) бирергә кирәк
3.5.Ачык тыңлауларда катнашу хокукы белән гаризаларны бирү вакыты: 2018 елның 2 сентябренә кадәр (тел.37-51-02)
4.Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге башкарма комитетына «Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге бюджетының 2018 елның 1

яртыеллыгында үтәлеше турында хисап» карар проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләнгән вакытта  әзерләргә һәм үткәрергә.
5.  Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

**Комсомолец авыл җирлеге  Башлыгы** **О.В. Сурова**